| | |
|---|---|
| СОВЕТ БАЛТАСИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«24» декабрь 2021ел №50

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Уставы нигезендә Балтач шәһәр җирлеге Советы карар бирде:

1. Расларга:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә;

муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеген 2 нче кушымта нигезендә;

муниципаль торак контроленең төп күрсәткечләрен һәм аларның максатчан күрсәткечләрен, муниципаль торак контроле өчен индикатив күрсәткечләрне 3 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач шәһәр җирлегенең төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык комиссиясенә йөкләргә.

Балтач шәһәр җирлеге башлыгы Р.Р.Нотфуллин